Бүгенге санда:



**Төньяк-көнчыгыш микрорайонын зур үзгәрешләр көтә. 2 бит**

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

# Дуслык

**Дружба**

**Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы**

Җомга **27** март 2015 ел

№ 22 (10551)

**28 мартка һава торышы:** аяз һава, явым-төшемсез, үзгәрүчән юнәлешле җил 4-5 м/с; температура көндез +1°С, төнлә -4°С

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

## *Абзац-информ*

### ГОМУМРОССИЯ СЪЕЗДЫНДА

Бүген Мәскәүдә узучы Гомумроссия мәгариф профсоюзларының чираттагы VII съездында 14 кешелек республика делегациясе составында Нурлат районы мәгариф хезмәткәрләре профсоюз оешмалары Советы рәисе Фәридә Сәгыйрова да бар. Съездда оешманың биш еллык эшенә йомгак ясалачак, мәгарифтә социаль-икътисадый хәл турында сүз барачак һәм үсеш планнары билгеләнәчәк.

### ХӘРБИ ЧАКЫРЫЛЫШ ҖИТӘ

Бу көннәрдә хәрби комиссариатның гражданнарны хәрби хезмәткә чакыру һәм әзерләү бүлеге начальнигы Илдус Мазияров ике көнлек методик җыеннарда катнаша. Ул ТР хәрби комиссариатының җыелу пунктында уза. Анда 1 апрельдән старт алачак язгы чакырылыш хакында да төгәл мәгълүматлар биреләчәк.

### АКТИВЛАРГА ДИПЛОМНАР БИРЕЛДЕ

Шәһәрнең 8нче урта мәктәбе укучысы Алия Вәлиуллина һәм Мамыктан Ольга Сизова "Костер" лагеренда волонтерларның профиль сменасында укулар уздылар. Нурлатның «SaMoStоятельные дети» наркотикларга каршы проектының актив әгъзалары дипломнарга да ия булып кайтканнар.

### НУРЛАТЛЫЛАР – ФИНАЛДА

Шәһәрнең 9нчы урта мәктәбе командасы "Сафта җырлап йөрү" республика смотрының Азнакайда узган зона этабыннан III урын яулап кайткан. Алар Нурлат данын республика күләмендә яклаячаклар. Быел чара Җиңүнең 70 еллыгына багышланган, һәм анда 9 районнан 5-7 сыйныф укучылары катнашкан.

# Үрнәк алыр кешеләр бар



Автор фотосы

ВӘЛИЕВЛАР БӘЙРӘМНӘН ЯҢА МАШИНАДА КАЙТЫП КИТТЕ

**"Ел хәйриячесе-2014" республика конкурсының җиңүчеләре арасында нурлатлылар да бар.**

Хәйриячелек республикада дәүләт сәясәтенең бер өлеше, һәм "Ел хәйриячесе" конкурсы да ел саен уздырылып килә. Чәршәмбе көнне исә "Корстон" комплексында үткән тантаналы чарада узган елга нәтиҗәләр ясалды. Нәтиҗәдә, Нурлаттан ел хәйриячесе исеменә "ТатРИТЭКнефть" җитәкчесе, ТР Дәүләт Советы депутаты Мөхәммәтвәли Хөснетдинов лаек булды. Тантаналы чарада Татарстан Президенты вазифаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миннеханов "Зур гаилә" республика хәйрия акциясе кысаларында Чулпаннан Гөлсинә Вәлиева гаиләсенә "Лада-Ларгус" автомобиле ачкычларын да тапшырды. Гөлсинә Вәлиева үзенең дүрт баласы янына тагын 4 сабыйны сыендырган, шуларның икесе – инвалид бала.

– Үземнең кечкенә улым авыру иде минем, - ди күпбалалы ана. – Шулай үз проблемаларым белән янып йөргәндә, мәчет картлары миңа игелек кылырга киңәш итте. Менә шул вакыттан башлап тәрбиягә бала алып үстерә башладым. Шөкер, Ходай ярдәмен бирә. Узган ел йорт-җирем янып киткәч, балалардан баш тартырга тәкъдим итүчеләр дә булды. Минем өчен иң мөһиме – гаилә, балаларым. Игелек җирдә ятмый, ди халык. Район башлыгы Равил Кузюров, ТР Дәүләт Советы депутаты, "Нурлатнефть" НГДУсы начальнигы Илгиз Салихов һәм игелекле кешеләр, авылдашлар, туганнар ярдәме белән бер ай эчендә яңа йортка күчендек. Авыл җирлеге Советы җир бирде, бу язда ук бакча утыртып, үз шәхси хуҗалыгыбызны булдырмакчыбыз. Инде туганнар ярдәме белән чебиләр, сарыклар да сатып алдык. Зур автомобиль турында күптән хыяллана идек. Республика башлыгына рәхмәт. Хәзер балаларым белән бергә рәхәтләнеп табигать кочагына чыгачакбыз, балыкка йөриячәкбез.

Яңа машина гаиләнең тагын бер күптәнге хыялын тормышка ашырырга ярдәм итәчәк. Хәзер алар зур гаиләләре белән Чистай балалар йортына кунакка барачак. Чөнки төпчекләре Виканың биредә тәрбияләнүче дус кызын да, туганнарын да кунакка алып кайтасы килә икән.

- Конкурска районнан 7 һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүче җиде гаиләне тәкъдим иткән идек, - ди район башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге начальнигы Ирина Савинова. – 8 ел дәвамында узучы республика конкурсында соңгы өч елда гына да районыбызда тәрбиягә бала алып үстерүче гаиләләребез 3 автобус һәм 2 "Лада-Ларгус" автомобиле белән бүләкләнде. Без район һәм республика җитәкчелегенә бик рәхмәтле.

Чарада "Күпбалалы мәдәни гаилә" номинациясендә Кәкре Атаудан Рәшит һәм Фәүзия Кәлимуллиннар гаиләсе дә катнашты.

**Зилия ӘКСАНОВА**

*Әлеге тантана турында тулырак "Атна вакыйгалары"ннан укый аласыз.*

**1 АПРЕЛЬГӘ КАДӘР РАЙОН ГАЗЕТАСЫНА ЭЛЕККЕГЕ БӘЯДӘН ЯЗЫЛЫП КАЛЫРГА ӨЛГЕРЕГЕЗ!**

АКТУАЛЬ

# Мошенниклар йокламый

**Бу, чыннан да, шулай. Мошенниклар нурлатлыларга нәкъ менә кичен һәм төнлә шалтыраталар бит.**

Мәсәлән, гыйнвар азагында ялгыз яшәүче пенсионер ханымның фатирына шалтыраталар. Таныш булмаган ир-ат үзен полиция хезмәткәре дип таныштыра һәм улыгыз юл һәлакәтенә юлыккан дип хәбәр итә. Хәлне йомып калыр өчен 70 мең сум акча кирәк булачак имеш. Ярый әле, пенсионер ханым шунда ук акча күчерергә ашыкмый, башта улына шалтырата. Әлбәттә инде, аның белән бар да тәртиптә була.

Икенче бер очрак киләсе көнне үк иртәнге 5тә була. Мошенниклар 75 яшьлек ханымнан 100 мең сум акча алырга тырышалар. Әмма барып чыкмый.

Кызганычка каршы, нурлатлыларның күбесе тиз ышанучан. Авылда яшәүче берәү таныш булмаган кешеләр шалтыратканнан соң, телефон аша 6 мең сум сала, тагы бер 80 яшьлек әби бөтенләй 12 меңен биреп җибәрә. Күптән түгел бер нурлатлы, таныш булмаган кешеләрнең газ исәпләгече кыйбыз дип әйтүләренә ышанып, 3,5 мең сум акчасын биреп чыгара.

МВДның Нурлат районы буенча бүлеге штабында хәбәр итүләренчә, инде быел гына да мошенниклардан 5 кеше зыян күргән. Социаль мошенниклыкка кагылышлы вәзгыять белән безне бүлек начальнигының беренче урынбасары Леонид Гаврилов таныштырды.

- Соңгы араларда мошенникларның корбаннары арасында 30–40 яшьлек кешеләрнең артуы борчый. Аларга банк карталарының блокировкалануы, лотерея отышы турында хәбәр җибәрәләр яки шалтыратып әйтәләр. Ел саен ТР МВДсы "Сак булыгыз: мошенниклар!" дигән профилактик операция үткәрә, ул үз эченә масштаблы аңлату эшләрен ала. Аның нәтиҗәләре дә яхшы. Кешеләр акчалары белән тиз генә хушлашырга ашыкмый. Кисәтелгән икән, димәк, коралланган да.

**Валентина ВАФИНА**

### МӘГЪЛҮМАТ ӨЧЕН

× *Картагызны блокировкалау турында хәбәр килдеме? Картаның үзендә күрсәтелгән банк службасы номерына шалтыратып белешегез.*

× *Бүләк оттыгыз, дип хәбәр җибәрделәр. Исегездә тотыгыз, бүләк откансыз икән, аның өчен бернинди акча да түләргә кирәкми.*

× *Замана мошенниклары – күпләр уйлаганча, чегән кыяфәтле кешеләр түгел. Алар европача киенгән.*

**× Янаулардан курыкмагыз, туганнарыгызга, полициягә 02, 2–11–25 (кәрәзледән 020 һәм 112) номерларына шалтыратыгыз.**

# РАЙОН ТОРМЫШЫ

ИНФРАСТРУКТУРА

## Заманча шәһәр: хыяллар чынга ашар

**Киң бульвар, спорт паркы, яшьләр өчен ял үзәге, күп катлы паркинглар... “Мондый уңайлыклар кайда икән?” дип баш ватмагыз. Бу – Нурлатның төньяк-көнчыгыш өлешен кору проекты.**

Планировка проекты расланган һәм гамәлгә ашырылырга әзер, инде җәмәгать тыңлаулары да үтте. Әлегә бу урында электр, элемтә линияләрен, кайбер инженерлык коммуникацияләрен генә күрергә мөмкин. Әмма якын киләчәктә яңа микрорайонда тулы канлы тормыш кайнаячак.

Биредәге җирнең күпчелек өлеше күпбалалы гаиләләргә шәхси төзелеш өчен бирелгән. Узган атнада булган җәмәгать тыңлауларында район башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге начальнигы Наталья Крайнова әйтүенчә, территорияне үзләштерү 2030 елга кадәр исәпләнгән. Әмма 2020 елга җәмгысе 9 мең квадрат метр территорияне биләп торачак 510 индивидуаль, шулай ук күп фатирлы йортлар кору фаразлана. Шул ук срокларда беренче хезмәт күрсәтү объектлары булдыру да планлаштырыла.

– Боларына кибетләре, кафе, элемтә бүлекчәсе булган күпфункцияле үзәк керә, – ди Наталья Крайнова. – Күпфатирлы йортларның беренче катларында тәртип саклаучы терәк пунктлар, банк бүлекчәләре, көнкүреш хезмәте предприятиеләре урнашачак. Шулай ук планировка проектында яшьләр өчен бассейнлы, спорт заллы ял үзәге, мәктәп, ике балалар бакчасы, спорт корылмалары, кибет-кафелар да каралган. Ә 2030 елга күпфатирлы йортлар тагы да артырга, 110 урынга балалар бакчасы, даруханә, офис биналары һәм башка объектлар пәйда булырга тиеш.

Шәһәрнең төньяк-көнчыгыш өлеше йортлар һәм хезмәт күрсәтү объектлары төзү белән генә чикләнмәячәк. Наталья Крайнова әйтүенчә, проектта урамны киңәйтү дә тәкъдим ителә: хәзер Кариев урамының йөрү өлеше 8 метр тәшкил итә, аны исә 16 метрга кадәр киңәйтү ниятләнә. Моннан тыш, яңа микрорайонда парковка урыннары белән проблема да хәл ителәчәк – бирелә күп катлы өч паркинг төзү каралган, анда 600ләп машина куеп булачак, ди.

Боларның барысын да тиз арада булыр, дип күз алдына китерүе кыен, әлбәттә. Заманча дәрәҗәдә төзергә ниятләнгән яңа микрорайон күп кенә нурлатлыларның хыялын тормышка ашырыр, мөгаен. Балалар бакчалары һәм мәктәпләр, кибет һәм даруханәләр, спорт заллары һәм паркингларның янәшәдә генә булуы матур хыял гына дисезме? Чынбарлык бу, һәм моны әлләни күп тә көтәсе калмады инде.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

ХӘБӘРЛӘР

### ЯШЕЛЛӘНДЕРҮ ПРОЕКТЫ

**Узган атнада табигатьне саклау инженеры Рөстәм Ногманов үсентеләр үрчетү буенча шәхси проектын гамәлгә ашырды. 2нче һәм 3нче мәктәпләрнең VII-VIII сыйныф укучыларын ул үсентеләр әзерләүгә җәлеп итте.**

– Пирамидасыман тупыл һәм тал ботакларын кисеп, аларны суга утырттык, – дип сөйли Рөстәм Ногманов. – Алар тамыр җибәрәчәк, апрель-майда, язгы агач утыртулар башлангач, укучылар әлеге үсентеләрне шәһәр урамнарына, мәктәп яны территорияләренә утыртачак.

Районның баш экологы әйтүенчә, бу проект укучыларны шәһәрне яшелләндерү мәсьәләсен хәл кылуга җәлеп итүгә юнәлтелгән. Шул рәвешле, укучылар 400ләп үсенте булдырырга ниятли.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

### ХИСАП ТЫҢЛАНДЫ, ДЕЛЕГАТЛАР САЙЛАНДЫ

**Бу дүшәмбедә “ТатРИТЭКнефть” хезмәткәрләренең конференциясе узды, анда 2014 елга нәтиҗәләр ясалды.**

Конференциягә предприятиенең Яр Чаллы, Алабуга һәм Нурлаттагы цех подразделениеләреннән хезмәткәрләр җыелды. Алар алдында “ТатРИТЭКнефть” директоры Мөхәммәтвәли Хөснетдинов һәм беренчел профсоюз оешмасы рәисе Гүзәл Әһлиуллина хисап тоттылар. Предприятие хезмәткәрләре проблемалы мәсьәләләр турында фикер алыштылар һәм хезмәтне саклау буенча яңа уполномоченныйлар сайладылар. Бу конференциядә РИТЭК хезмәткәрләренең 2 апрельдә Мәскәүдә узачак конференциясенә Татарстан подразделениесеннән катнашачак делегатлар да сайланды.

**Гөлназ ГАЗИЗОВА**

### АШЛАМАЛАР КАЙТА БАШЛАДЫ

Узган атна азагыннан районның авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренә Татарстан Президенты әмере буенча республика бюджетыннан бүленгән средстволарга аммиак селитрасы кайта башлады. Быел ул 2300 тонна (тәэсир итүчән матдәгә күчереп исәпләгәндә бер гектарга 11 кг. ) кайтарылачак. Районда язгы чәчү эшләренә тәэсир итүчән матдәгә күчереп исәпләгәндә бер гектарга 60 кг. исәбеннән 10 мең тоннадан артыграк ашлама кирәк булачак.

### ТЕХНИКАНЫ КОМИССИЯ ТИКШЕРӘ

Чәршәмбедән район комиссиясе хуҗалыкларга чыгып, техниканың язгы чәчүгә әзерлеген тикшерә башлады. Районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе, Россельхозцентр, Гостехнадзор белгечләреннән торган комиссия чәршәмбе көнне “ВЗП-Билярск”, “Нурлат сөте”ндә, кичә һәм бүген башка хуҗалыкларда булып тракторлар һәм авыл хуҗалыгы машиналарының әзерлеген бәяли. Республика комиссиясенең тикшерүе исә апрель башларында көтелә.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

СӘЛАМӘТЛЕК

### ЯШЬЛӘР ИРТӘНЕ ЗАРЯДКАДАН БАШЛАДЫ

**25 март иртәсе 350 Нурлат укучысы өчен гадәти булмаганча – ачык һавада зарядка белән башланып китте.**

Массакүләм спорт чарасында шәһәр мәктәпләре укучылары, “Яшь гвардия”, “СМС-балалар” оешмалары әгъзалары һәм оештыручылар үзләре – Нурлат районының Иҗтимагый палатасы әгъзалары Ленар Әһлиуллин белән Рөстәм Ногманов катнаштылар. Дәртле музыка астында спорт хәрәкәтләрен “Яшь гвардия” активистлары күрсәтеп тордылар. 6 минутлык флешмобның никадәр уңай тәэсирләр бүләк итүен катнашучыларның йөзләреннән күрергә мөмкин булды.

- Бүген безнең иртәбез гомумшәһәр зарядкасыннан башланды, без аннан бик күп уңай энергия алдык. Мондый чаралар яшьләрне сәламәт яшәү рәвеше алып барырга чакыра һәм без мондый зарядканың ешрак үткәрелүен телибез, - дип тәэсирләре белән урталкашты 1нче мәктәп укучысы Лилиана Гарифуллина.

Районның Яшьләр иҗтимагый палатасы рәисе Ленар Әһлиуллин әйтүенчә, киләсе шундый зарядка майда планлаштырыла икән.

**Гөлназ ГАЗИЗОВА**

КӨН КАДАГЫНДА

## Сату азайган да бит...

**ЮХИДИ хезмәткәрләре уяулык күрсәтмәсә, кемнеңдер җиңел акча эшләү теләге күпме гомерне корбан иткән булыр иде икән: инспекторлар автоюлда бер машинадан 90 литр спиртлы продукция алганнар.**




МОНДЫЙ ПРИБОР КОНТРАФАКТЛЫ АЛКОГОЛЬ ПРОДУКЦИЯСЕН АЧЫКЛАРГА ЯРДӘМ ИТӘ, - ДИ ДӘҮЛӘТ АЛКОГОЛЬ ИНСПЕКЦИЯСЕ БЕЛГЕЧЕ АЛИЯ ГАТИНА

Әлеге очрак февральдә булган. Юл хәрәкәте иминлеге инспекторлары махсус чара барышында Самара номерлы машинаны туктаталар. Аның багажнигында спиртлы сыешлык белән биш литрлы 18 баллон табыла.

Алкоголь продукциясен законсыз җитештерү һәм сатуга бәйле хокук бозулар әледән-әле теркәлеп тора: март башында гына да өй шартларында ясалган этил спиртлы продукция сату факты буенча 5 административ беркетмә төзелә. Мисал өчен, шикәрчеләр бистәсендә яшәүче берәү тикшерү сатып алуы барышында бер көн эчендә ике тапкыр эләгә. Беренче очракта ул 50 сумга 0,375 литрлы спиртлы сыешлык сата, соңрак 100 сумга тагы 0,95 литрлысын “озата”. Калган 5,5 литр продукциясен полиция хезмәткәрләренә ирекле рәвештә тапшырырга туры килә. Авыл халкы да “йокламый”: тикшерү сатып алуы барышында Андреевка, Рус Богдашкиносы, Биляр Озерода өйләреннән спиртлы продукция сатучылар ачыклана. Бер караганда, ялган продукциядән тормышка куркыныч яналса, икенче яктан бу легаль продукция сатуга да йогынтысын ясый. Республика дәүләт алкоголь инспекциясенең Чистай территориаль органы начальнигы Александр Саунин алкоголь продукциясе әйләнеше өлкәсендә хокук бозуларны ачыклау һәм булдырмау буенча ведомствоара комиссиянең үткән атнадагы утырышында әйтүенчә, ялган продукцияне законсыз сату очракларын ачыклау буенча эшне көчәйтергә кирәк.

– Узган ел Нурлат районы буенча легаль алкоголь продукциясен сату 14 проценттан артыгракка, ә 2012 елдан бирле 34 процентка кимегән. Ягъни эшмәкәрләр алкоголь продукциясе сатудан 34 процентлап “җыеп” бетерә алмаганнар дигән сүз, – диде ул. Ә республика буенча бу сан тагы да саллырак – 1 млрд. сумга җыела.

Әгәр дә алкоголь сату күләменең кимүе нурлатлылар азрак эчә башлавын аңлатса, бу күренешне уңай яктан да бәяләргә булыр иде анысы. Чөнки татарстанлыларның сәламәт яшәү рәвешенә республика җитәкчелеге зур игътибар бирә, хәер, ил күләмендә дә шундый сәясәт алып барыла. Әмма алда китерелгән фактлар легаль продукция урынын ялган аракы, көмешкә яулый баруы турында сөйли. Ә моңа юл куярга ярамый, әгәр дә кеше алкоголь кулләна икән, һичьюгы ул сыйфатлы булсын иде. Әнә, утырышта да ерак урнашкан кибетсез авылларга беренчел ихтыяҗдагы товарлар, шулай ук алкоголь продукциясе дә сатучы күчмә сәүдә оештырылачак, диелде. Дөрес, бу уңайдан өйдә җитештерелгән хәмер сату фактлары булган авыл җирлекләре башлыкларына да кызарырга туры килде, ни дисәң дә, үрнәк итеп күрсәтмәделәр бит, ә җитешсезлекләрне әйтеп, участок уполномоченныйлары белән берлектә халык арасында актив эш алып барырга куштылар.

Бу проблема авыл җыеннарында да күтәрелде. Район башлыгы Равил Кузюров ул чакта ук җитешсезлекләргә игътибар юнәлткән һәм үз файдасына башкалар гомерен куркыныч астына куючыларны катгый җәзага тартырга кушкан иде.

Бу продуктка ихтыяҗ булганда, соравы да кимемәс анысы, әлбәттә инде, продукция легаль булырга тиеш. Кызганычка каршы, ялган хәмерчеләр дә ялган аракы алып кайту һәм сатуның әллә нинди ысулларын уйлап таба торалар. Тикшерү сатып алулары барышында йолып алынган һәм экспертизага җибәрелгән контрафактлы продукция кайбер закон бозучыларны туктатыр, башкаларына гыйбрәт булыр, бәлкем: тикшерү нәтиҗәләре буенча җинаять эше кузгату турында да карарлар кабул ителәчәк бит.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

### КИЛЕШҮЛӘР ТӨЗЕЛӘ

*Бүгенге көнгә предприятие, оешмалар, эшмәкәрләр хезмәткәрләре белән 809 килешү төзегән. Бу хакта район башкарма комитетыннан хәбәр иттеләр. Соры хезмәт базарын легальләштерү буенча эш дәвам итә.*

**“Кайнар линия” телефоны: 2-06-69.**

### ЭШМӘКӘРЛӘР ӨЧЕН ОЧРАШУ

**31 мартта, 10.00да** район Советында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен Татарстан Республикасында эшмәкәрлеккә ярдәм итү, үстерү һәм яклау мәсьәләләре буенча очрашу була. Анда ТР икътисад министры Артем Здунов, ТР Президенты каршындагы эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча уполномоченный Тимур Ногманов, ТР Сәүдә-сәнәгать палатасы Идарәсе рәисе Шамил Агеев катнашачак.

# ВАКЫТ. ВАКЫЙГА

ҖИҢҮНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

## “Исәнлектә күрешик!”

**Яңа Әмзә авылында яшәүче Фатыйма апа Сәмәрханова шул көннәрдә генә 95 яшен тутырса да, сәламәтлегенә зарланмый, камил акылында һәм гел хәрәкәттә. Әбинең тормышны яратып яшәвенә сокланмаган кеше юктыр, мөгаен.**

Әлбәттә, ул чорның күпчелек кешеләре кебек үк, Фатыйма әби дә кыенлыкларны күп күргән. Фатыймага нибары 4 ай булганда, әтисе үлеп китә. Өч бала белән ялгыз калган әнисенә дә, балаларга да тормыш җиңел бирелми. 14 яшеннән колхозга эшкә чыккан кызның башлангыч белем алырга да мөмкинлеге булмый. Сугыш башлангач, 21 яшьлек Фатыйма Буа, Шөгер районнарына урман кисәргә китә. Аннан окоплар, землянкалар казу... Җиңү хәбәрен исә чәчүгә дип орлык ташыган вакытта ишетә.

Уку-язуга да үзлектән өйрәнә ул. Бүгенге көндә русчасын да, татарчасын да, хәтта латинчасын да шартлатып укый, кирәген яза.

– Үземә укырга мөмкинлек булмады, гомерем буе гади эштә идем, әмма балаларыма югары белем бирергә тырыштым, - ди әби. – Шөкер, кызларымның барысы да укытучы һөнәрен үзләштерде.

Тормыш иптәше, Бөек Ватан сугышы ветераны Сәет ага белән алар 9 балага гомер бирәләр. Шуларның бүген 5се исән, әбиебез 13 оныкка, 13 оныкчыгына шөкерана итеп яши.

– Беркайчан үземне ялгыз хис итмәдем, - ди әби. – Һәрвакыт балаларым, оныкларым, якыннарым, күршеләрем янымда булды. Ә озын гомеремнең сере – һәрчак хәрәкәттә булудадыр, дим. Аннан балаларымның, оныкларымның матур яшәве, алар өчен күңелем тыныч булуы да үз йогынтысын ясагандыр. Хәзерге тормышка шөкерана итеп яшәргә кирәк: бөтен нәрсә бар бит.

– Әни беркайчан эштән курыкмады, - дип сүзгә кушыла кызы Фәнилә дә. – Үзе текте, бәйләде. Чисталыкны бик ярата. Өстендә һәрвакыт матур кием булды аның. Кулыннан килмәгән эше юк. Эшне ирләрнеке, хатын-кызларныкына бүлеп тормый. Ул безнең өчен баръяклап та үрнәк булды.

Гомер бәйрәмендә юбилярга Россия Президенты Владимир Путин, район башлыгы Равил Кузюровның котлауларын һәм бүләкләрен район башкарма комитеты җитәкчесе Әсхәт Габдуллин




САН

**Әмзә авыл җирлегендә ел башыннан өч кеше 90, 95 яшьлек юбилейларын билгеләп үткән.**

җиткерде. Шунда ук ветеран толына, тыл хезмәтчәненә Җиңүнең 70 еллыгына багышланган юбилей медале дә тапшырылды.

Фатыйма апаның озын гомерле булуына һәм матур яшәвенә Әсхәт Габдуллин да сокلануын яшермәде.

– Йөз яшегезне дә шулай бергә каршы алырга насыйп булсын, - диде ул юбилярга теләкләрен җиткереп. – Иң мөһиме, сәламәтлек һәм якыннарыгызның кайгыртуын тоеп яшәгез.

“Мондый игътибар һәм зурлавыгыз өчен үзегезгә рәхмәт инде ”, - диде күңеле булган әби кунакларны 100 яшьлек гомер бәйрәменә дә чакырып.

**Зилия ӘКСАНОВА**

## Яшьлеге яу кырында узган

**Күптән түгел Красномайск поселогында яшәүче Бөек Ватан сугышында катнашкан Роза Ивановáны да 90 яшьлек юбилее белән котладылар.**

Роза Петровнага РФ Президенты Владимир Путинның котлавын һәм бүләкләрне район башлыгы урынбасары Флюра Ногманова җиткерде. Шунда ук ветеранга Җиңүнең 70 еллыгы медален дә тапшырды. “Без бу Җиңүне күп мәшәкатьләр белән яуладык. Дәһшәтле сугыш берәүне дә аямады. Безгә, япь-яшь кызларга да автоматлар тотып постларда басып торырга туры килә иде”, – дип истәлекләрен уртаклашты Роза Петровна.

Роза Иванова фронтка киткәнче телеграфчылар курсын уза, анда Морзе әлифбасын камил өйрәнә. Ул 303нче авиация полкында сугыша, Варшаваны азат итүдә катнаша, “Батырлык өчен” медале белән бүләкләнә. Сугыштан соң иминият агенты булып эшли, шулай да гомеренең күпчелек өлешен гаиләсенә һәм балаларына багышлый. Ире белән 5 бала тәрбияләп үстерәләр алар. Роза Иванова бүгенге көндә улы Веналий һәм килене Валентина янында яши.

**Маргарита ЛИТТА**

## Сөйләүчеләр барда тыңлап калыйк

**Ветераннарыбыз исән чакта истәлекләрен теркәп калырга ашыгыйк дип, шул көннәрдә без – 7нче сыйныф укучылары, сугыш ветераны Миңлегөл әби Хәлиуллина янында булып кайттык.**

Чистай шәһәрендә фельдшер-акушерлар әзерләү курсын тәмамлаган кыз хезмәт юлын Биләр районында башлап җибәрә. Сугыш башлангач, Нурлатта яралылар өчен эвакогоспиталь оештыралар. Миңлегөл апа үз теләге белән шунда эшкә керә. Көнне төнгә ялгап эшләргә туры килә аларга. Сугышның беренче көннәрендә үк яраланган, күңел төшенкелегенә бирелгән солдатларны дәвалау бер дә җиңел булмагандыр. Миңлегөл апаның шифалы кулы, тәмле теле дә күп авыруларның савыгуына, алга таба күңелләрендә яшәүгә өмет уятуга сәбәпче булгандыр дип уйлыйбыз. Сугыш тәмамланганнан соң, Миңлегөл апа район хастаханәсендә хезмәт куя. Озак вакытлар Киекле авылында эшли. Миңлегөл әби бик олы яшьтә инде, ул бүгенге көндә улы Рәис абый тәрбиясендә яши. “Ветераннар янәшәдә” акциясе кысаларында мәктәбебезнең “Дуслык” балалар оешмасы хөрмәтле ветераннарыбызга истәлекле бүләкләр дә әзерләде.

**Регина ШАРАПОВА, Киекле мәктәбе**

“НУРЛАТНЕФТЬ” НГДУсында

## Нефтьчеләр сәләтләрен күрсәтте




СӘХНӘДӘ - УДСВНның НЕФТЬ ЧЫГАРУ ОПЕРАТОРЫ РИНАТ ФӘЙЗЕТДИНОВ

**20 мартта район мәдәният йорты сәхнәсендә “Нурлатнефть” НГДУсының Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышланган үзешчән сәнгать смотр-конкурсының сайлап алу туры узды.**

Компетентлы һәм профессиональ жюри хөкеменә предприятиенең җиде цехы һәм идарә аппараты үз номерларын тәкъдим итте. Хәер, бу очрашуны конкурс дип кенә атау да килешмәс. Чөнки һәр катнашучы үз чыгышына күңелен биреп кенә калмады, ә Бөек Җиңү көнен якынайткан, аның өчен башларын салганнарга хөрмәтен дә күрсәтергә тырышты. Күз яшьләре чыгарырлык тематик җырлар, шигырьләр, театраль тамашалар һәм җентекләп сайланган киемнәр – болар барысы да нефтьчеләрнең бу чарага зур җаваплылык белән карауларын раслый иде.

Конкурска аерата ЦППД һәм ЦКППН масштаблы әзерләнгәннәр, алар көчле алкышларга лаеклы яртышар сәгатьлек программа күрсәттеләр. Һәм катнашучыларның дулкынлануына, әзерлек вакытының аз булуына да карамастан, концерт бик матур килеп чыкты. Лилия Билданова, Надежда Митянина, Рәсимә Туктарова, Валентина Әюпова, Айрат Хөсәенов, Лилия Минзарипова, Рамил Әхмәтвәлиев, Ринат Фәйзетдинов, Светлана Мурзина, Ленар Садретдинов һәм Лилия Абдуллинаның чыгышлары берәүне дә битараф калдырмады. Григорий Лисенков гитара белән Олег Газманов репертуарыннан “Офицеры” җырын бик матур башкарды. Кашыкчыларның гаилә дуэты Николай һәм Тимур Маматовлар осталарча “Яблочко” көен уйнады. Смотр-конкурсның даими лауреаты Радик Җиһаншин баянда уйнап сөендерсә, Рәмзис Шәкуров дәртле татар биюен башкарды. Матур традиция буенча, конкурста нефтьчеләрнең балалары да катнашты. Алар арасында “Созвездие-Йолдызлык” республика фестиваленең лауреаты Дмитрий Николаев, яшь скрипкачы һәм төрле конкурслар лауреаты Гөлназ Гайнетдинова, Дарья Ендирякова һәм бертуганнар Екатерина белән Олеся Морозовалар бар иде.

Барлык чыгышлардан соң, “Нурлатнефть” НГДУсы профкомы рәисе Ринат Мөхәммәтҗанов катнашучыларның шулкадәр җитди әзерләнүләренә соклануын җиткерде һәм шәп концерт өчен һәммәсенә рәхмәтен әйтте.

“Бүген без күп талантлар күрдек. Минемчә, шактый чыгышлар тагы да күбрәк тамашачыга җиткерелергә тиештер”, – дип үз бәясен бирде жюри рәисе, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре Сәмигулла Рәхмәтуллин.

28 мартта Түбән Камада “Татнефть” ААҖ тарафыннан Җиңүнең 70 еллыгына багышлап уздырылучы үзешчән сәнгать смотр-конкурсының икенче сайлап алу туры булачак. Анда “Нурлатнефть” хезмәткәрләре дә үзләренең иң яхшы номерларын тәкъдим итәчәк.

**Марина КОРНИЛОВА**

*Реклама хокукында*

ХОКУК ӘЛИФБАСЫ

## ЗАКОНДА ҮЗГӘРЕШЛӘР БАР

**Ана капиталы түләүләре буенча законга үзгәрешләр кертелде. Хәзер ана капиталы средстволары торак сатып алуга (төзүгә) микрофинанс оешмасыннан алынган займнар буенча төп бурыч һәм процентларны түләү өчен тотыла алмый.**

- Законнардагы үзгәрешләрдә торак кулланучылар кооперативларына карата да өстәмә таләпләр каралган. Хәзер ана капиталын керү яки пай взносы хисабына дәүләти теркәлү узганнан соң үз эшчәнлеген өч елдан артыграк алып барган кооперативларга гына юнәлтергә мөмкин. Моннан тыш, законнардагы үзгәрешләр Пенсия фонды идарәсенең территориаль органнарына китерелгән документларның тиешле органнар тарафыннан бирелү фактын тикшерү хокукы да бирә. Элегрәк гамәлдә булган закон нигезендә, Пенсия фондының территориаль органы бары тик ана капиталына дәүләт сертификаты биргәндә гариза бирүче китергән документлардагы мәгълүматларның дөреслеген генә тикшерә иде. Бу очракта ана капиталына сертификат алу белән аның средстволарыннан файдалану арасында озак вакыт үтәргә мөмкин иде, - дип үзгәрешләргә аңлатма бирде Пенсия фондының Нурлат районы буенча идарәсе начальнигы Рушания Шакирова.

**Валентина ВАФИНА**

ЯШӘЕШ

ПРОБЛЕМА

# БУШ ЙОРТЛАР:

**Колбай Морасаның үзәк урамында кечкенә генә иске йортның ике моңсу тәрәзәсе урамга текәлгән. Кайчандыр ярән чәчәкләренә күмелеп утыра иде ул тәрәзәләр, ә курчак өе кебек якты, бизәкле йортта тәмле телле, ачык чырайлы Кафия апа Миндубаева яши иде. Ике улы үсеп Казанга китеп төпләнде, үзе дә күптән мәрхүм инде, ә хуҗасыз йорт җиргә сеңә бара, сеңә бара...**


Автор фотосы

# ТӘРТИП САЛАСЫМЫ, СҮТЕП АЛАСЫМЫ...

Кызганыч, һәр авылда дистәләгән шундый иясез йортларны күрергә мөмкин хәзер. Быелгы авыл җыеннарында хуҗасыз йортлар темасы иң күп күтәрелгән темаларның берсе булды.

–Хуҗасыз йортлар–авыл өчен баш бәласы ул,–ди Бикүле авыл җирлеге башлыгы Рияз Садыйков.–Бердән, ни милек салымы, ни җир салымы җыя алмыйбыз; икенчедән, авылның йөзен бозып торалар; өченчедән, ут-күз ягыннан да куркыныч тудыралар, хуҗасыз йортлар бомжлар җыелыр өчен дә бик кулай урын.

Авыл җирлеге башлыгының шулай ачынып сөйләве өчен нигез бар булып чыкты: әлеге авыл җирлегендә 48 хуҗасыз йорт исәпләнә икән бит. Әнә, Мансур Латыйповның янгыннан соң калган йорты әле дә хәрабә хәлендә, 12 бертуганның берсе дә ни кайтып төзәтергә, ни сүтеп җыештырырга теләк белдерми. Мәрхүм Гафур Әхмәтов, Гариф Сәгыйров йортлары да буш, варислары булса да йорт-җирне карамыйлар. Рифкать Садретдинов бабасы йортын үз артына теркәтсә дә ,йорт-җирен, бакчасын тәртиптә тоту турында уйламый. Березовка авылында 5 йортта гына кеше яши, калганнары ташландык хәлгә кереп бара. Йортларның хуҗасыз калу сәбәпләре төрле: я туганнар үзара уртак тел таба алмыйлар, яки кыйммәт хак куеп, сата алмыйлар, яки нәселдә беркем калмаган булып чыга. Соңгысы– бик бәхәсле очрак.

–Әмма син аны сүтәргә тотынып кара әле, хәзер әнә очы бер туганы табыла да куя,–ди Рияз Хатыйпович үз тәҗрибәсеннән чыгып.

Бу йортларның авыл халкы өчен дә куркыныч тудыруы турында Чүлпан авылы җыенында да ишеттек.

–Һәр ике якта да өчәр буш йорт, быел җәй берсенә җыелып кайтып төшкәннәрен күргәч, бакча утыртучылардыр, дип сөенгән идем. Кая ул–төне буе җырлап күңел ачтылар, мин төн узганчы ут-күз чыкмагае дип саклап йөрдем,–диде олы яшьтәге ханым чара күрүләрен үтенеп.

Салдакай авылыннан безгә шалтыраткан бер ханымның (исемен атамавыбызны үтенде) туган нигезе Абрыськинода икән. Ул энесе артында булса да, энесе башка йорт сатып алган, ә туган нигез 10 елдан артык инде буш тора.

–Үткәндә, йөрәгем әрни: туган нигез бит, –ди ханым, ичмаса, сүтеп алсын иде ул йортны дип өзгәләнеп.

Әйе, туган йорт хакы, нигез хакы дигән нәрсә мәсьәләнең әхлакый ягы, шуңа да авыл җирлеге җитәкчеләре тарафыннан бик телгә алынмады. Анысы кайчандыр шушы нигездә туып-үскән, канат ярган, ата-анасы яшәгән адәм баласының намусында булырга тиештер. Мин беләм: туган йортларын сатып китеп читтә яшәүчеләр нигезләрен күрергә дип махсус кайталар, аны тәртиптә тоткан яңа хуҗаларга рәхмәт әйтеп, ата-аналары рухына сәдака биреп китәләр. Шуңа да ташландык йорт ул беренче чиратта үз ата-анаңны, нәселеңне кадерсезләү, дип бәяләргә кирәктер.

Ни генә булмасын, хуҗасыз йортлар проблемасын хәл итү юллары каралыр сәгатькә җиткәнбез икән. Телдән генә авыл җирлекләре башлыкларына киңәш бирүчеләр дә табылды: янәсе, һәр авыл җирлегенең үз территориясен тәртиптә тоту кагыйдәләре эшләнгән, анда яшәүчеләрнең бурычлары күрсәтелгән. Әмма шунысы бар: авыл җирлеге советы җиргә кагылышлы вәкаләтләрне ике яклы килешү нигезендә район башкарма комитетына тапшырган булып чыкты. Димәк, җиргә кагылышлы алыш-бирешләрне бары район башкарма комитеты гына һәм тиешле законнар нигезендә генә тормышка ашыра ала. Әмма халыкка тәэсир итүнең башка бик гади чарасы да бар икән. Соңгы вакытта Киекле авыл җирлеге башкарма комитеты бу юнәлештә актив кына эш башлап җибәргән һәм нәтиҗәләре дә күз алдында. Шәһәргә якын авыл җирлеге булу сәбәпле, биредә 105 йорт дача йорты буларак файдаланыла, ягъни хуҗалары язгы-җәйге чорда гына кайтып торалар икән.

– Алар белән проблема юк, йортлары теркәлгән,– ди авыл җирлеге башлыгы Рәфис Ганиев.– Аннан кала теркәлмәгән 49 йорт бар иде әле. Җыеннан соң аларга уведомление тараттык, аңлату эшләре үткәрдек, хәзер менә 23 кеше үз милкен теркәү эшен башлап җибәрде,–ди авыл җирлеге башлыгы.

Алай гына да түгел, пай җирләре белән дә шундый актив эш башланган икән. Үз пай җирләренә документы булмаган 93 кешедән бары 25е генә рәсми кәгазь алырга өлгермәгән. Алары да акрынлап тартылыр, дип ышаналар биредә. Җыеннан соң Фома авыл җирлегендә дә теркәлмәгән 12 йорт варислары белән аерым сөйләшүләр алып барганнар.

– Хәзер 5 йорт теркәлү стадиясендә,–диде авыл җирлегенең ул чактагы башлыгы Ирек Шәрәфетдинов.

Димәк, бу уңайдан авыл җирлекләре башлыкларының предметлы эш итүләре дә кирәк.

Әэш йортүнең законлы юлы турында безгә шәһәр прокуроры **Рамил ГАРИФУЛЛИН** аңлатма бирде:

**– Буш йортлар проблемасын хәл итү максатыннан 2007 елда Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты каршында хуҗасыз йортларны ачыклау буенча комиссия төзелгән булган. Әмма, прокурор тикшерүе барышында ачыкланганча, хокукый база булмау сәбәпле, комиссия нәтиҗәле эшләп китә алмаган, соңгы елларда комиссия тарафыннан хуҗасыз йортларны ачыклау тукталган.**

**Гражданлык Законы ташландык күчемсез милеккә ике хокукый статус бирүне күздә тота: бу–хуҗасыз күчемсез милек һәм выморочный торак бина. Әмма әлеге статусларны бирү өчен, суд процессын да кертеп аерым бер процедураны уздыру кирәк.**

**Йортларны хуҗасыз яки выморочный дип тануга хокукый нигез булдыру максатыннан, район прокуратурасы тарафыннан җирле үзидарә советларына хуҗасыз һәм выморочный йортларны ачыклау һәм аларны муниципаль милек буларак исәпкә алу тәртибе турында Нигезләмә проекты юлланды. Ул авыл җирлекләре башлыкларына үз торак пунктларында тәртип салуга хокукый мөмкинлек бирер,–диде Рамил Таһирович.**

Сәкинә ХӘЙРУЛЛИНА

КЫСКАЧА

## ҖИҢЕП КАЙТТЫЛАР

РФ Пенсия фондының Нурлат районы идарәсе коллективы сигез идарә арасында узган зона ярышларыннан җиңү яулап кайтты. Әлеге ярышлар ведомство Спартакиадасы кысаларында Чистайда узды. Идарә спортчылары гомумкоманда нәтиҗәләре буенча I урын алдылар. Бүгенге көндә алар ярымфиналга әзерләнә, анысы Кукмарада узачак.

## КАНИКУЛЛАР КҮҢЕЛЛЕ ҮТӘ

Язгы каникулның беренче көннәреннән район мәктәпләрендә белем алучы 40 бала район башкарма комитеты аша Нурлатның "Нурсан" санаториендә ял итә. Биредә балалар өчен сәламәтләндерү чаралары белән бергә күңелле ял программасы да каралган.

ФЕСТИВАЛЬ

# "Салават күпере" дуслыкны ныгыта

**Сишәмбе көнне Нурлатта "Салават күпере" республика балалар-үсмерләр милли мәдәният фестиваленең сайлап алу туры үтте.**

Республикада милләтләр салават күперенең төсләре сыман күп һәм төрле. Һәм төрле милләт балалары бер сәхнәгә чыгып, үзләренең мәдәни һәм сәнгати байлыкларын тәкъдир иткәндә аеруча ачык күренә бу. Әнә, Нурлат сәхнәсендә республиканың 8 районыннан 300гә якын бала көн дәвамында төрле милләт халыкларының җыр-биюләрен генә түгел, борынгыдан сакланып килгән гореф-гадәтләрен, йолаларын да ачык төсләр, якты кәеф белән күрсәтә алдылар. Татарстанның Мәдәният министрлыгы, Халыклар дуслыгы йорты һәм ассамблеясы оештырган әлеге фестивальнең сайлап алу турын ачу тантанасында район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Әлфия Галәветдинова катнашучыларга җылы теләкләрен җиткерде.

Фестиваль сәхнә чыгышлары белән бергә декоратив-гамәли иҗат үрнәкләрен барлауны да күздә тота. Бу яктан төрле районнарның мәдәният йортлары, балалар үзәкләре каршында эшләп килүче түгәрәкләрдә әзерләнгән кул эшләренә карап хәйран калырлык. Нурлатның балалар иҗаты үзәгендә эшләп килүче түгәрәктә Әлфирә Карымовада шөгыльләнүче Әдилә Садыйкова исә үз куллары белән ясалган бизәнү әйберләреннән никах җыелмасын тәкъдим итте.

- Болар - татар кызларының борынгыдан килгән чулпы, беләзек, изү, алкалары. Аларның барысын да натураль ташлардан, милли үзенчәлекләрне истә тотып ясарга тырыштым, - ди кыз. Әдилә әле түгәрәккә йөреп, яшьтәшләре белән милли киемнәр коллекциясе булдыруда да катнашкан, фестивальдә аларны да күрсәттеләр.

Үзәкнең тагы бер педагогы Людмила Цветкованың укучылары исә сәйләннән ясалган татар халык бизәкләре фрагментларын тәкъдим итте.

